**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«25» август 2023 ел № 36/3

**2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакындамәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 5968,54 мең сум, чыгымнар буенча 2822,17 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
-2023 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен Боерган авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүнеәлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова